## ЯҢА ЗАМАН УКЫТУЧЫСЫ: МИНЕМ КҮЗАЛЛАВЫМ

Соңгы елларда безнең тормышыбыз бик нык алга китте. Тормышыбызның һәр өлкәсенә фән- техника казанышлары буларак компьютерлар, электрон исәпләү машиналары килеп керде. Заман кешеләрнең акыллы, тирән белемле булуын таләп итә. Белемне бит безгә кадерле укытучыларыбыз бирә!

Яңа заман башлангыч сыйныф укытучысы нинди булырга тиеш соң?

Башлангыч сыйныф укытучысы...Балага әнисе кебек үк кадерле кеше бит ул. Җиде яше әле генә тулган бала мәктәп бусагасын кыяр-кыймас атлап керә. Юкка гына борчылган икән бит. Әнә елмаеп-көлеп әнисе кебек үк шәфкатьле, сабыр, мөлаем укытучы каршы алды...Шул көннән башлап бала аны чын күңелдән ярата башлый.Яратмаслыкмыни? Укытучысы һәр соравына җавап бирә, берәрсе рәнҗетсә, юатырга әллә нинди матур сүзләрен таба, иркәләп башыннан сыйпый, өенә киткәндә елмаеп озатып кала... Санап та бетерерлек түгел укытучының гүзәл сыйфатларын. Гомер-гомергә шундый булган башлангыч сыйныф укытучылары. Заман үзгәрсә дә, башлангыч сыйныф укытучылары нәкъ менә шундый булып калсыннар. Мин аларны бүтәнчә итеп күз алдыма да китерә алмыйм. Укытучылар да заманыбыз кебек тупасланса, мәрхәмәтсезгә әйләнсә, укучыларның мәктәпкә аяк атлыйсы да килмәс иде.

Башлангыч сыйныф укытучысы заманнан бер адым да калышмыйча атларга тиеш, минемчә. Ул балалар аласы бик күп, бик күп белемнәрнең нигез ташын салучы кеше. Нигез нык булганда гына нидер төзергә мөмкин бит. Үзебезнең гимназиянең башлангыч сыйныф укытучыларына карыйм да исем китә. Ничек өлгерәләр барысына да? Аларга бит хәзер икеләтә җаваплылык артты. Бу уку елы башында һәр башлангыч сыйныф укучысы өчен ноутбуклар кайтты, кабинетлар интерактив такталар, мультимедиа проекторлар белән җиһазландырылды. Укытучыларга күпме мәшәкать артты. Ул кадәр техниканың барысын да эшләтә белергә кирәк бит. Тырышалар укытучылар...Чын яңа заман укытучылары!

Яннарында балалар бөтерелә, һәрберсенең ул матур әйберләрне тотып карыйсы, аларда тизрәк эшлиселәре килә. Тик укытучының җаны тыныч түгел, күңелен бер нәрсә борчый. “Бу кадәр техника сабыйлар өчен бик зарарлыдыр инде ул “,-дип борчыла икән укытучы. Аннан тагын шунысы да бар: компьютерга ышанып ,бала үзе уйламаска өйрәнә лә. Кулга каләм тотып тырыша-тырыша беренче хәрефләрне язарга өйрәнүгә җитәмени ул ноутбукларда язу. Көне буе техника белән мәш килеп, укучыларга игътибар азая. Бала бала инде ул,укытучыдан җылы сүз көтә, беләмени ул укытучыга заманнан калышмыйм дип күпме тир түгәргә кирәклекне.

Тырыша укытучы, барысына да өлгерергә тырыша.

Соңгы елларда  мәктәпне тәмамлаучы яшьләр икътисадчы, юрист кебек һөнәрләрне сайлыйлар. Педагогик уку йортларына күбесенчә башка уку йортларына укырга керә алмаган, имтиханнарда азрак балл җыйганнар бара. Бу безне бик борчый торган проблема. Кемнәр килер безнең белемле, уңган, тырыш, алтын куллы укытучыларыбызга алмашка? Шулкадәр тирән белем бирә алырлармы алар укучыларына? Минем уйлавымча, иң-иң белемлеләр генә укытучы булырга хокуклы. Ләкин андыйлар бүтән уку йортларында белем ала. Яңа заман укытучыларның абруен какшатты шул...

Яңа заман башлангыч сыйныф укытучысы...Һәрвакыт шат күңелле булсын иде ул. Тормыш мәшәкатьләрен уйлап, күңелсезләнеп  йөрмәсен иде. Хезмәт хакын җитәрлек итеп түләсәләр, бар күңелләрен яраткан эшләренә генә бирерләр иде, минемчә.

Яңа заман укытучысының тышкы кыяфәтен  дә башкачарак күзаллыйм мин. Уйлап табасы иде алар өчен берәр эш формасы, үзенчәлекле кием. Укытучы икәнлекләре әллә каян күренеп торыр иде дә һәркем килеп аларга баш ияр иде. Баш ими яныннан үтмәсләр иде, чөнки иртәме-соңмы һәрберебез

укытучыларыбызның безне кеше итәр өчен күпме тырышканын, күпме йокысыз төннәр үткәргәнен аңлый.